
# «Китап» радиосы дөрес юлда»

Зилә **Мөбәрәкшина**

«Китап» радиосының мобиль кушымтасын смартфоннарга 10 мең тапкыр йөкләгәннәр. Баш мөхәррир Алмаз Миргаязов тыңлаучыларның ни сәбәпле радионы яратып кабул итүе хакында сөйләде.

**– «Китап» радиосының мобиль кушымтасын App-Store һәм GooglePlay сервисларында 10 меңнән артык тапкыр йөкләгәннәр. Бу — зур санмы?**

– Әлеге кушымта Россиядән бигрәк чит илдә яшәүче милләттәшләр күңеленә хуш килде. Алар һәр милли продуктка игътибар белән карый һәм бер-берсеннән белешеп, илдән-илгә шалтыратышып, хәбәр итешеп тора. Әле бер көнне генә Испаниядә яшәүче танышым: «Алмаз, бездә радио ни өчендер эшләми башлады. Синдә гаеп юк, алайса?.. Тукта әле, мин Прагадагы танышымнан белешеп карыйм,




*«Китап» радиосын йөкләп алыр өчен QR-код*

аныкы эшли микән», — дип шалтыратты.

**– Радио кайсы ягы белән үзенчәлекле?**

– «Китап» радиосының миссиясен баштан ук билгеләдек, без чикләнгән аудитория – әдәбиятны, мәдәниятне кабул итәргә әзер булганнар өчен, аларга гына кирәк булган формада һәм микъдарда милли продукт җитештереп тарабыз. «Милли радио» форматын популяр (попса) музыка форматына күнеккән тамашачы күп очракта кабул итмәячәк. Аудиториянең чикләнгән булуы безнең өчен зур өстенлек, чөнки без шуның белән уникаль, кабатланмас. «Китап» радиосының җәмгыятькә булган беренчел файдасы – кешене тормыш мәшәкатеннән туктатып, татар милләтен саклап калган традицион кыйммәтләргә игътибарын җәлеп итү.

**– Әдәби әсәрләрне халыкка ишеттерү өчен, артистларны, җәмәгатьчелек эшлеклеләрен дә җәлеп итә башладыгыз…**

– Дөресен әйткәндә, бу әле башы гына. Әлеге өлкәдә без пассив, чөнки шигырьләрне һәм әдәби әсәрләрне укуга кызыксынучанлык шактый күп кешедә бар. Инстаграмда һәм башка социаль челтәрләр аркылы «мин дә шигырь укыйм әле», – дип әйтүчеләр бермә-бер артты. Авылдагы клуб мөдирләреннән алып, танылган кешеләргә кадәр «минем дә сезгә килеп, яздырып китәсем килә», яисә «яздырылган материалларны җибәрергә буламы?» кебек мөрәҗәгатьләр бихисап.

**– «Китап» радиосында нинди яңалыклар көтелә?**

Алга таба без социаль челтәрләр аудиториясендә эшчәнлекне көчәйтергә уйлыйбыз. Андагы аудитория ярдәмендә берничә проектны тормышка ашырырга ниятебез. Мәсәлән, тиздән #минӘгъләмнеукыйм дип исемләнгән флешмоб башлап җибәрергә ниятлибез.

Илдә-көндәге вәзгыять тагын үзгәреп куймаса, радиобыз Казанда 98,6 FM ешлыгында октябрь–ноябрь айларында эшли башлар дип өметләнәбез. FM-га чыккач, безнең эшчәнлегебез түгәрәкләнер дип уйлыйм.

Икенче яктан, төрле буын аудиториясенең консерватив форматка тартылуы да безне сөендерә.

**Татарстанның атказанган артисты**
**Айгөл Бариева:**
«Гомумән, әхлакка, тәртипкә, чисталыкка өнди торган әйберләр, радио-телевидение, китаплар, концертлар, матбугат чаралары булсынмы ул, тәртипкә илтә торган юллар кирәк. Дөнья шулкадәр үзгәрде, күңел пакьлеккә тартыла. Шуңа күрә, «Китап» радиосы хезмәткәрләренә рәхмәт әйтәсем килә, алар татар халкына кирәкле эш башкара. Дус-танышларымнан да уңай фикерләр ишетәм. Алдагы көннәрдә дә уңышлы эшләргә насыйп булсын, «Китап» радиосы дөрес юлда. Аннан тайпылмыйча алга таба атларга язсын».

**Продюсер**
**Җәүдәт Гыйльманов:**
«Мондый радио бик кирәк дип саныйм, аның аша татарның мирасы булган кыйммәтле җырларны ишетәсең, никадәр китаплар тыңлыйсың! Аудиокитаплар яңгыраткан башка радиолар бар микән тагын, белмим. Радиода яңгыраган әсәрләр татар әдәбиятына кызыксыну тудыра».

**Төркиядә укучы аспирант**
**Айгөл Зара Кәбирова:**
«Юкка гына «туган якның кадерен белер өчен, китеп кара ерак җирләргә», — дип әйтмиләр икән… Милли радиода уйнатылган җырлар, укылган әсәрләрдән өзекләр аша Актанышыма, аның урман-болыннарына, су буйларына, бабай һәм дәү әниемнең йортына, киң ямь-яшел ишегалды-бакчаларына, Чаллыма, әти-әниемнең өенә, яшүсмер чакларга кайтып киләм. Милли радио Төркия татарлары өчен файдалы булыр дип уйлыйм».

КУЛЛАНУЧЫ ХӘБӘРЛӘРЕ

## Кулланучы исәп-хисап җиһазлары өчен җавап бирми

2020 елның 1 июленнән электроэнергия исәпләү җиһазлары өчен җаваплылык кулланучылардан энергетика компанияләренә күчә дип хәбәр итте Россия Энергетика министрлыгы.



**2018 елның 27 декабрендә чыккан «Россия Федерациясендә электр энергиясен (егәрлеген) исәпкә алу системалары үсүгә бәйле рәвештә Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 522 номерлы федераль закон нигезендә 2020 елның 1 июленнән кулланучыдан исәп-хисап җиһазларына хезмәт күрсәтү һәм тикшерү буенча бөтен җаваплылык алына. Ул күп фатирлы йортларда гарантияле тәэмин итеп торучыларга һәм башка кулланучылар (аларга хосусый торак төзелешендә яшәүчеләр да керә) белән булган очракта челтәр компанияләренә күчә.**

**Хәзер кулланучы үзе җаваплы булган зонага (фатирда яки торак йорт төзелгән җир участогында) кергән исәп-хисап җиһазларының сакланышын гына күзәтеп торырга тиеш. Кулланучыларның элек тоткан чыгымнары хәзер гарантияле тәэмин итеп торучыларда һәм челтәр оешмаларында булачак.**
**Исәп-хисап җиһазларына карата мәҗбүри таләпләр әлегә үзгәрешсез кала. Әмма 2022 елның 1 гыйнварыннан интеллектуаль исәпкә алу җиһазлары урнаштыру башлана, алар энергияне исәпкә алуның интеллектуаль системаларының төп элементы булачак.**

## Сәгатьләрне алмаштырып булмый

**«Оныгымны мәктәптә контрольдә тоту өчен GPS системалы акыллы сәгать алган идем. Оныгыма дизайны ошамады. Мин аларны башкага алмаштыра аламмы?**

**А. Пахоменко»**




**«Кулланучылар хокукларын яклау» Россия законының 25 маддәсенең 1 пункты нигезендә, кулланучының ундүрт көн дәвамында (сатып алу көнен санамыйча) сыйфаты сакланган, азык-төлек булмаган товарны шул ук сатучыдан шундый ук товарга алмаштырып алу хокукы бар. Әгәр сатып алынган товар формасы, габаритлары, фасоны, төсе, размеры яки комплектациясе буенча туры килмәсә, алмаштырып була. Моның өчен сатып алынган товар кулланылмаган, аның товар кыяфәте, пломбалары, фабрика ярлыклары сакланган булырга, шулай ук товар чегы яки касса чегы, яисә товарга акча түләнгән булуны раслый торган башка документ булырга тиеш.**

**Әмма алмаштырып һәм кире кайтарып булмый торган товарлар исемлеге бар. Ул Россия Хөкүмәте 1998 елның 19 гыйнварында чыгарган №55 карарда расланган. Исемлекнең 11 нче пунктында көнкүрештә кулланыла торган техник яктан катлаулы товарлар, шул исәптән кесә һәм кул сәгатьләре, механик, электрон-механик яки ике һәм аннан да күбрәк функцияле электрон сәгатьләр дә бар.**
**Шулай итеп, Законның 25 маддәсе нигезендә, балалар өчен GPS системалы акыллы сәгатьләрне кире тапшырып яки алмаштырып булмый.**